| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НОВОИШТЕРЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЯҢА ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 15 октябре №24

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 25 октябрендәге 4 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында (2017 елның 30 маендагы 11 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 35 номерлы, 2019 елның 6 июнендәге 17 номерлы, 2019 елның 9 августындагы 23 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым Кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Яңа Иштирәк ылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 25 октябрендәге 7 номерлы «Җир салымы турында» карарына ( 2017 елның 30 маендагы 11 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 35 номерлы, 2019 елның 6 июнендәге 17 номерлы, 2019 елның 9 августындагы 23 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яки торак пунктларда авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составына кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җирләргә карата 0,3%";»

2) 2 пунктның 3 абзацын «(шәхси торак төзелеше өчен, эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылучы өчен алынган җир участокларыннан тыш)” сүзләре белән тулыландырырга;

3) 2 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Шәхси хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (тапшырылган) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия

Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында " 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,23%.»;

4) 2 пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Файдалы казылмалар эшләү ,тимер юллар, автомобиль юллары, ясалма эчке су юллары, причаллар, пристань, тимер һәм автомобиль юллары, су юллары, труба үткәргечләр, кабель, радиорелей һәм һава элемтә линияләре, радиофикация линияләре, электр тапшыру һәм конструктив элементларның һава линияләре һәм корылмалары, эксплуатацияләү ,тоту, төзү ,реконструкцияләү, төзекләндерү, җир өсте һәм җир асты биналарын үстерү өчен кирәк булган объектлар, корылмалар, җир өсте һәм җир асты, транспорт, энергетика һәм элемтә җайланмаларын урнаштыру; җир өсте корылмаларын һәм иярченле элемтә инфраструктурасын, космик эшчәнлек объектларын, оборона, куркынычсызлык объектларын урнаштыруга билгеләнгән җир участокларына 1,31% мөнәсәбәттә».

5) 2 пунктның 10 абзацын үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Яңа Иштирәк авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы, Совет рәисе Г.Р.Мәүлетова